СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.05.2025 № 58/6

На №__________ от______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 19 ноябрендәге 19/11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 04 августындагы 480-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 19 ноябрендәге 19/11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.3 пунктын өстәргә:

«Оператив-эзләү эшчәнлеген яки Россия Федерациясенең куркынычсызлыгын тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазифаи затларына мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатында, эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар, хәбәрнамәләр җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.»;

1.2. 6.3 пунктта «мөрәҗәгатьне яңа адреска юнәлтү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә» сүзләрен «шулай ук мөрәҗәгатьне яңа адреска юнәлтү турында хәбәрнамә җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә яисә Бердәм порталда шәхси кабинет адресын (уникаль идентификаторны) куллана» сүзләренә алыштырырга;

1.3. 8.4 пунктында «электрон документ формасында» сүзләреннән соң «яки кулланганда Бердәм порталда гражданның шәхси кабинет адресы (уникаль идентификатор) буенча» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров